МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 декабрь 2021 ел № М 529

Шәһәр Хакименең 2018 елның 9 июлендәге М 299 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2018 елның 9 июлендәге М 299 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның 2 пунктчасында «муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) җитәкчеләре» сүзләрен «муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләре, устав капиталында муниципаль берәмлекнең йөз процент катнашу өлеше булган хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләре (алга таба – оешмалар җитәкчеләре)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 пунктның 2 пунктчасында «муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) җитәкчеләре» сүзләрен «оешмалар җитәкчеләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) 12 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче башка муниципаль хезмәткәрләр; муниципаль хезмәт мәсьәләләре һәм комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә ала торган белгечләр; дәүләт органнары, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынучы оешмаларның вәкилләре; комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү турында

мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле оешма җитәкчесенең, муниципаль хезмәткәрнең вәкиле, – комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле оешма җитәкчесенең, муниципаль хезмәткәрнең үтенече нигезендә һәр очрак өчен аерым һәм комиссия утырышына кадәр өч көн алдан, комиссия рәисе карары буенча яисә комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы карары буенча.»;

4) 15 пунктның 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«- муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эш башкару нияте турында белдерүе.».

5) түбәндәге эчтәлектәге 18.1 пункт өстәргә:

«18.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы 2 пунктчасының 6 абзацында күрсәтелгән белдерү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының муниципаль хокукый акты белән расланган башка түләүле эш башкару нияте турында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан белдерү тәртибе нигезендә карап тикшерелә»;

6) түбәндәге эчтәлектәге 35.1 пункт өстәргә:

«35.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы 2 пунктчасының алтынчы абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәткәр тарафыннан башкарыла торган башка түләүле эш аның тарафыннан вазыйфаи бурычларын объектив үтәүгә йогынты ясамый һәм йогынты ясый алмый, димәк, мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр үтәлгән дип билгеләргә;

2) муниципаль хезмәткәр тарафыннан башкарыла торган башка түләүле эш аның тарафыннан вазыйфаи бурычларын объектив үтәүгә йогынты ясый һәм йогынты ясарга мөмкин, димәк, мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр үтәлмәгән дип билгеләргә.

Муниципаль хезмәткәрнең эш бирүчегә алдан хәбәр итмичә башка түләүле эш башкаруы ачыкланган очракта, комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга тәкъдим итә.».

7) 4 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Оешма җитәкчесенең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турындагы хәбәрен комиссия тарафыннан карап тикшерү тәртибе

51. Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булып комиссиягә оешма җитәкчесенең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәре (алга таба – белдерү кәгазе), шулай ук нигезле бәяләмә һәм башка материаллар керү тора.

52. Әлеге Нигезләмәнең 51 пунктында күрсәтелгән белдерү кәгазен алдан карау Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе (алга таба – персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе) тарафыннан гамәлгә ашырыла, белдерү кәгазен карау нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерләнә.

53. Әлеге Нигезләмәнең 52 пунктында каралган нигезле бәяләмәне

әзерләгәндә персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсенең вазыйфаи затлары, әлеге Нигезләмәнең 51 пункты нигезендә белдерү кәгазе биргән оешмалар җитәкчеләреннән язмача аңлатма алырга хокуклы, ә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе) билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар җибәрергә мөмкин.

Белдерү кәгазе, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар кергән көннән башлап җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла.

Запрослар җибәрелгән очракта белдерү кәгазе, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар, белдерү кәгазе кергән көннән башлап 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән артмаган срокка.

54. Комиссия рәисе, аңа Башкарма комитетның хокукый актында каралган тәртиптә комиссия утырышы үткәрү өчен нигезләрне үз эченә алган мәгълүмат кергән очракта, 10 көн срокта комиссия утырышы датасын билгели. Бу очракта комиссия утырышының датасы күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән башлап 20 көннән арткан вакытка билгеләнергә тиеш түгел.

55. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү, комиссия әгъзаларын комиссия утырышында фикер алышуларга чыгарыла торган материаллар белән таныштыру персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсенең вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

56. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, әлеге Нигезләмәнең 51 пункты нигезендә белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесе катнашында үткәрелә. Белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесе комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында белдерү кәгазендә күрсәтә.

57. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда, әлеге Нигезләмәнең 51 пункты нигезендә белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесе булмаганда үткәрелә:

1) әгәр белдерү кәгазендә белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесенең комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтмәләре булмаса;

2) әгәр комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәр алган, белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесе комиссия утырышына килмәсә.

58. Комиссия утырышында оешма җитәкчесенең аңлатмалары тыңлана һәм утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кагылышлы материаллар карала. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының, оешма җитәкчесенең үтенече буенча башка затлар тыңланырга һәм алар тарафыннан тапшырылган материаллар каралырга мөмкин.

59. Комиссия әгъзалары һәм комиссия утырышында катнашкан затлар комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны башкаларга җиткерергә хокуклы түгел.

60. Әлеге Нигезләмәнең 51 пунктында күрсәтелгән белдерү кәгазен карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты булмады дип танырга;

2) белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин дип танырга. Бу очракта комиссия белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрүне тәкъдим итә;

3) белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесе тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр үтәлмәде дип танырга. Бу очракта комиссия түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

- Башкарма комитет Җитәкчесенә, белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесенә карата конкрет җаваплылык чарасы куллануны;

- белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча чаралар күрүне.

61. Комиссия белдерү кәгазе биргән оешма җитәкчесе тарафыннан административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре булган эш итү фактын (эш итмәү фактын) ачыклаган очракта, комиссия рәисе әлеге эш итү (эш итмәү) турындагы мәгълүматны һәм әлеге фактны раслаучы документларны 3 көн срокта, ә кирәк булганда – кичекмәстән, хокук саклау органнарына җибәрә.

62. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының яшерен тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавышы буенча кабул ителә (әгәр комиссия башка карар кабул итмәсә).

63. Комиссия карары утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарлары Башкарма комитет Җитәкчесе өчен тәкъдим итү характерына ия.

64. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) комиссия утырышының датасы, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең формулировкасы, мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле оешма җитәкчесенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп;

в) комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алган мәгълүматның чыганагы, мәгълүматның керү датасы;

г) оешма җитәкчесенең һәм башка затларның карала торган мәсьәләләрнең асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм алар ясаган чыгышларның кыскача эчтәлеге;

е) башка мәгълүматлар;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) комиссия карары һәм аны кабул итү нигезе.

65. Кабул ителгән карар белән килешмәгән комиссия әгъзалары үзләренең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, бу фикерне комиссия утырышы беркетмәсенә беркетеп кую мәҗбүри һәм аның белән оешма җитәкчесе таныштырылырга тиеш.

66. Комиссия карарыннан өземтә, комиссия утырышының беркетмәсе имзаланган көннән соң биш эш көне эчендә, мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле оешма җитәкчесенә, шулай ук Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелә.

67. Комиссия карарына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев